# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
«Урта Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең
Урта Тигәнәле авыл торак пунктында
2023 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2022 елның 13 октябреннән** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Урта Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Урта Тигәнәле авыл торак пунктында гражданнар җыены

## КАРАР ИТТЕ:

1. 2023 елда Алексеевск муниципаль районының «Урта Тигәнәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендәге Урта Тигәнәле авыл торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә, 1 төркем инвалидлардан,тыл хезмәтчәннәреннән, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына сроклы хезмәткә алынучы гражданнардан тыш.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

1. Авыл эчендәге юлларны төзү һәм ремонтлау
2. Күмү урыннарын төзекләндерү
3. Кыш һәм җәй көннәрендә юлларны чистарту
4. Төбен чистарту белән күлне төзекләндерү
5. Су белән тәэмин итү трассасын ремонтлау һәм салу
6. БВС һәйкәле төзелеше;
7. Янгын гидрантын көйләү

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта Урта Тигәнәле авыл җирлеге башкарма комитетына акчаларны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт бирергә.

3.Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Урта Тигәнәле авыл җирлеге мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http:// alekseevskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алексеевск муниципаль районы
Урта Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы Хамәтвәлиев И.К.